| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2024 г.Казань № 504-46/тко-2024

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2025 елга чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм җитештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм җитештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2024 ел, №32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән бердәм тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторының җитештерү программасын расларга.

4. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 23 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 504-46/тко-2024
карарына 1 нче кушымта

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2025 елга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы тарафыннан хезмәт күрсәтүгә чик дәрәҗә бердәм тарифлар, сум/куб.м. | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 1 | "Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе" идарәче компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 549,58 | 598,49 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 149 статьясының 2 пунктының 36 пунктчасы кулланылмый.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 504-46/тко-2024
карарына 2 нче кушымта

**Оешманың җитештерү программасы**

**1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Җайга салынулы оешма** | "Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе" идарәче компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | |
| Урнашкан урыны | 420087, Татарстан Республикасы, Казан ш., Родина ур., 8 й., 10 офис | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2025 |

**2 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру исемлеге**

| № | Аталышы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары |
|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** |
| 1 | Объектларны агымдагы ремонтлау | мең сум | 3 430 907,31 |
| | Агымдагы ремонт | мең сум | 0,00 |
| 3 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 |

**3 нче бүлек. Каты коммуналь калдыкларның планлаштырылган күләме**

| № | Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** |
| 1 | Каты коммуналь калдыкларның күләме | мең куб.м. | 7 172,22 |

**4 нче бүлек. Финанс ихтыяҗлары күләме**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** |
| 1 | Төбәк операторының үз чыгымнары | мең сум | 2 400 883,20 |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны транспортлау чыгымнары | мең сум | 2 017 444,09 |
| 1.2 | Сату чыгымнары (шикле бурычлар) | мең сум | 95 822,12 |
| 1.3 | Шартнамәләр төзү һәм аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары | мең сум | 247 238,53 |
| 1.4 | Контейнерлар һәм бункерлар сатып алу һәм тоту чыгымнары | мең сум | 33 830,24 |
| 1.5 | Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүгә банк гарантиясе бирүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 6 548,22 |
| 2 | Каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру һәм (яисә) | мең сум | 1 101 939,83 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | куму чыгымнары | | |
| 3 | Алынмаган керемнәр / Төшеп кала торган чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 4 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 5 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 |
| 6 | Исәпләнгән эшкуарлык табышы | мең сум | 14 053,44 |
| 7 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре | мең сум | 85 969,16 |
| 8 | Кирәкле тулай табыш, өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча | мең сум | 3 430 907,31 |

**5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| № | Чараның аталышы | план чоры |
|---|---|---|
| 1 | Җитештерү программасын гамәлгә ашыру кысаларындагы чаралар каралмаган. | |

**6 нчы бүлек. Объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең план һәм факт күрсәткечләре**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2025 ел |
| Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә файдаланыла торган объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар өчен билгеләнде | | | |

**7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап**

Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән.